**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**2024 елда «Алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү программаларына ярдәм итү» грантларын гамәлгә кую турында**

«Алдынгы инженерлык мәктәпләре» федераль проекты кысаларында Татарстан Республикасында эшләүче югары белем бирү мәгариф оешмалары базасында оештырылган алдынгы инженерлык мәктәпләренә дәүләт ярдәме күрсәтү максатларында, «Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» 1998 елның 18 июнендәге 1661 номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясы һәм «Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» 2010 елның 2 августындагы 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. 2024 елга «Алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү программаларына ярдәм итү» грантын (алга таба шулай ук – грант) гамәлгә куярга.

2. Кушымта нигезендә 2024 елда «Алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү программаларына ярдәм итү» грантын алучылар исемлеген расларга.

3. Татарстан Республикасы бюджетының грантлар түләүгә бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме 411 780,9 мең сум тәшкил итә дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

2024 елда субсидияләр рәвешендә «Алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү программаларына ярдәм итү» грантларын бирү тәртибен расларга;

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан һәр грант алучыга түләнәчәк грант күләмен билгеләргә;

әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә;

грантларның максатчан файдалануын контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

әлеге Указны үтәүне тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2024 ел, 25 май
№ 388

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2024 елның «25» маендагы
388 номерлы Указы белән
расланды

**2024 елда «Алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү программаларына ярдәм итү» грантын алучылар исемлеге**

1. «Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциячел булмаган оешмасы.
2. «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе.
3. «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе.
4. «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе.
5. «Нефть югары мәктәбе» Әлмәт дәүләт технология университеты» дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе.

___________